**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

16.08.2022 **Чирмешән авылы** №455

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 5 ноябрендәге 455 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 5 ноябрендәге 455 номерлы карары белән расланган бакчачылык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 пунктының 13 пунктчасын бәян итәргә: «13) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата РФ Җир кодексының 39.18 статьясының 1 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамә бастырып чыгарылган һәм урнаштырылган;»

1.2. 3 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә: «3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре»

3.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән гомуми билгеләр белән берләштерелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт

күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.14, 2.15 пунктлары һәм әлеге бүлек белән билгеләнде.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар җыелмасын кабул итү һәм карау;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга (pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т.Айбатов